**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

_01.07.2021_ ___739-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе турында

Россия Федерациясенең «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары участоклары турында геологик мәгълүматка, аны үткәргән өчен түләү күләме һәм тәртибе турында» 2005 елның 11 февралендәге 69 номерлы карары, Россия Федерациясе Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Каты файдалы казылмалар запасларын исәпләү буенча дәүләт экспертизасына тапшырыла торган материалларның составы һәм аларны рәсмиләштерү кагыйдәләренә таләпләрне раслау турында» 2011 елның 23 маендагы 378 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасының «Җир асты байлыклары» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәгә таянып боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе составы.

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И. Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А. В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының __________ № __ боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе (алга таба – Республика комиссиясе) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына (алга таба – Министрлык) йөкләнгән бурычларны үтәү максатында төзелгән коллегиаль орган булып тора һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә, шулай ук чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан 500 кубометрга кадәр тәшкил иткән эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган гомуми таралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасын үткәрүне оештыру вәкаләтләренә ия.

1.2. Республика комиссиясе үз эшчәнлегендә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары участоклары турында геологик мәгълүматка, аны үткәргән өчен түләү күләме һәм тәртибе турында» 2005 елның 11 февралендәге 69 номерлы карарына, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Каты файдалы казылма запасларын исәпләү буенча дәүләт экспертизасына тапшырыла торган материалларның составы һәм аларны рәсмиләштерү кагыйдәләренә таләпләрраслау турында» 2011 елның 23 маендагы 378 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасының «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Законына һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга караган Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Республика комиссиясе Татарстан Республикасы җир асты байлыкларын рациональ файдалану, гомумтаралган файдалы казылма запасларын һәм җир асты суларын дәүләт исәбенә алу өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатлар өчен, җир асты байлыкларыннан файдалану өчен түләү билгеләү, җир асты байлыкларыннан файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы җир асты

байлыкларының кыйммәтен яисә куркынычын билгели торган бүтән үзлекләре турында мәгълүматның дөреслеген бәяләү эшчәнлеген алып бара

1.4. Запасларга дәүләт экспертизасы ятманы геологик өйрәнүнең теләсә кайсы стадиясендә тәкъдим ителә торган геологик материаллар гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларының, аларның сәнәгать әһәмиятендәге, тау, гидрогеология, экология һәм аларны чыгаруның башка шартларына объектив бәя бирергә мөмкинлек биргән очракта үткәрелергә мөмкин.

1.5. Республика комиссиясе әгъзаларына коммерция серен тәшкил итүче мәгълүматны үз мәнфәгатьләрендә куллану, шулай ук, экспертлана торган объектларның тәкъдим ителгән документларында тиешле гриф билгеләү юлы белән җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан билгеләнгән очракта, аны өченче затларга тапшыру һәм тарату тыела.

1.6. Республика комиссиясе карарлары, нинди ведомствога һәм милек формасына каравына карамастан, тау чыгару һәм геологик разведка эшләре алып баручы барлык җир асты байлыкларыннан файдаланучылар өчен мәҗбүри булып тора.

## 2. Республика комиссиясенең бурычлары

Республика комиссиясенең бурычы булып документларны һәм материалларны анализлау юлы белән башкарыла торган дәүләт экспертизасы тора:

- эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларын исәпләү буенча, аларны чыгару күләме тәүлегенә 500 куб. метрдан да ким булмаган күләмдә тәшкил итә;
- җир асты байлыкларында гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын санау өчен кондицияләрне техник-икътисадый нигезләү (алга таба – ТИН) буенча;
- эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган, аларны чыгару күләме тәүлегенә 500 куб. метрдан да артмаган, геологик разведка эшләре (алга таба – ГРЭ) нәтиҗәләре буенча һәм бу запасларны яңадан бәяләү өчен файдаланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларының торышын оператив рәвештә үзгәртү буенча;
- гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларын, табылган файдалы казылма ятмаларын исәпләү буенча;

## 3. Республика комиссиясенең функцияләре

3.1. Министрлыкка йөкләнгән бурычлар нигезендә, Республика комиссиясе түбәндәге функцияләрне башкара:

- гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары, шулай ук җир асты байлыкларының башка үзлекләре турында, аларны үзләштерүнең техник-икътисадый күрсәткечләрен дә кертеп, геологик мәгълүматка экспертиза оештыра һәм үткәрә;
- гомумтаралган файдалы казылмаларга вакытлыча кондицияләрнең ТИН экспертизасы нәтиҗәләрен карый, раслый яисә эшләп бетерү өчен кире кайтара;

- гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларын исәпләү материаллары буенча башкарылган геологик-разведка эшләренең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген, гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты суларының, гидрогеологик, инженер-геологик, технологик һәм башка махсус тикшеренүләрнең сыйфат күрсәткечләрен өйрәнү тулылыгын анализлый һәм бәяли һәм ятмаларны алга таба эш стадияләрендә, шулай ук якындагы мәйданнарда ГРЭ юнәлеше буенча (кирәкле өстәмә эшләр һәм тикшерүләр уздыруны кертеп) киңәшләр бирә;

- гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларын исәпләү материалларын анализлый һәм гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын һәм җир асты суларын эзләү срокларын кыскарту буенча ГРЭның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү буенча тәкъдимнәр әзерли;

- республика балансында исәпкә алына торган барлык ятмалар буенча запасларны санау өчен даими һәм вакытлыча кондиция параметрларын раслый;

- лицензияләгәндә җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары буенча алдагы стадияләрдә һәм ятмаларны үзләштерү этапларында тәкъдимнәр әзерли;

- ятмаларда табылган запасларны расламау сәбәпләрен анализлый, ГРЭны оптимизацияләү буенча киңәшләр бирә, эшкәртелмәгән ятмалар буенча запасларны эшкәртү тулы өлешендә каплау мөмкинлеге яки мөмкинлеге булмау турында нәтиҗә бирә, расланмаган запасларны исәптән төшерү турында карарлар кабул итә;

- кызыксынучы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар катнашында разведка ятмалары буенча запасларны оператив еллык исәпләү материалларын карый, аларны дәүләт исәбенә кую мөмкинлеге турында карарлар чыгара, запаслар артуын билгели;

- методик мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе запаслары буенча дәүләт комиссиясе һәм территориаль комиссия белән, шулай ук Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

- гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты суларын чыгаруга бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдалану объектлары буенча геологик материалларга дәүләт экспертизасын (җир асты саклагычларын һәм башка җир асты корылмаларын төзү һәм җир асты байлыкларының бөтенлеген бозуга бәйле башка хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру) оештыра.

3.2. Республика комиссиясенең түбәндәгеләрне күзәтеп тора:

- гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларын, шулай ук минераль чималга вакытлыча кондицияләр проектларын раслауга оешмалар тарафыннан тапшырыла торган материалларның тулылыгын һәм сыйфатын;

- конкрет ятмаларда гомумтаралган файдалы казылмалар запасларының һәм җир асты суларының разведка запасларының дөреслеген.

4. Республика комиссиясенең составы һәм эшен оештыру

4.1. Республика комиссиясе составына Министрлык җитәкчеләре, Министрлыкның минерал чимал һәм су ресурслары идарәсе һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлекләре җитәкчеләре һәм

белгечләре керә.

4.2. Республика комиссиясенең саны һәм персональ составы Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры тарафыннан раслана.

4.3. Республика комиссиясе әгъзалары түләүсез нигездә эшли.

4.4. Республика комиссиясенең эшенә рәис – Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры җитәкчелек итә, Республика комиссиясе рәисе урынбасары булып җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары тора.

4.5. Республика комиссиясе рәисе булмаганда, аның функциясен Республика комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

4.6. Республика комиссиясе рәисе:

- Республика комиссиясе утырышын җитәкли һәм үткәрә;
- Республика комиссиясенең җаваплы сәркатибен билгели;
- запасларга дәүләт экспертизасы нәтиҗәләренраслый.

4.7. Республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе:

- Республика комиссиясенең эшен алып баруны оештыра;
- Республика комиссиясенең эш планнары проектларын эшләүне тәэмин итә;
- Республика комиссиясе әгъзаларын аның эше, урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә;
- Республика комиссиясе рәисе күрсәтмәсе буенча, Республика комиссиясенең эшенә бәйле башка функцияләрне башкара.

4.8. Республика комиссиясенең оператив эшенә җитәкчелек итә:

- Республика комиссиясе рәисе урынбасары;
- Республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе.

Республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе Республика комиссиясе рәисе белән килештерү буенча Республика комиссиясенең утырышын җир асты байлыкларыннан файдаланучылар каравына тапшырылган материалларны карау максатларында оештыра. Республика комиссиясе утырышының вакыты һәм урыны турында җаваплы сәркатип тарафыннан Республика комиссиясенең барлык әгъзаларына да хәбәр ителә.

Республика комиссиясе утырышы нәтиҗәләре буенча Республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе тарафыннан дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә бәян ителә, аны Республика комиссиясенең әгъзалары имзалый һәм кул куйганнан соң 5 эш көне дәвамында Республика комиссиясе рәисе раслый.

Эксперт комиссиясенең аерым әгъзалары эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе белән килешмәгән очракта, алар «аерым фикер» тамгасы белән бәяләмәгә кул куялар. «Аерым фикер» аның нигезләмәсен үз эченә алган аерым документ белән рәсмиләштерелә.

5. Республика комиссиясенең хокуклары

5.1. Республика комиссиясе хокуклы:

җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга, дәүләт хакимияте органнарына, оешмаларга үз компетенциясе мәсьәләләре буенча киңәшләр бирергә;

тау чыгару предприятиесе булган һәм ГРЭ уздыручы оешмалардан

Министрлыкка күрсәтмәләр соратып алырга:

- минераль чималга даими кондицияләр һәм гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын һәм эшкәртелә торган ятмалардагы җир асты суларын исәпләү һәм (яки) яңадан исәпләү материаллары проектларын бәяләү, аларны бәяләү, элек раслаганнан соң үткәрелгән эксплуатацияләү һәм геологик разведка эшләре нәтиҗәсендә шактый үзгәргән проектларны бәяләү;

- минераль чималга вакытлыча кондицияләр проектларын эшләү һәм разведкалау һәм эшкәртелә торган ятмалар буенча запасларны санау буенча еллык планнар төзү (графиклар);

- минераль чималга кондицияләрнең ТЭИны тикшерү һәм җир асты байлыкларындагы гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын һәм җир асты суларының запасларын санау өчен кирәкле геологик һәм башка материаллар;

РКЗ утырышларына тапшырылган документларны һәм материалларны җаваплы башкаручыларны җәлеп итәргә.

5.2. Файдалы казылмалар һәм җир асты суларының запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре, шулай ук эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан да ким булмаган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына экспертиза уздыру өчен, РКЗ штаттан тыш экспертлар сыйфатында файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү өлкәсендә җитәрлек эш тәҗрибәсе булган югары квалификацияле белгечләрне һәм (яки) эксперт оешмасын җәлеп итәргә хокуклы. Җәлеп ителә торган штаттан тыш экспертлар саны карала торган материалларның катлаулылыгы белән җайга салына.

6. Республика комиссиясе эшчәнлеген оештыруны тәэмин итү

6.1. Республика комиссиясенең утырышлары, әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

6.2. Комиссиянең барлык карарлары аның утырышларында ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Республика комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының «әйе» һәм «каршы» тавышлары тигез булганда рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

6.3. Файдалы казылмалар запасларының вакытлыча кондицияләрен һәм запасларын ТИН карап тикшерү, рәсмиләштерү һәм раслау өчен махсус инструкцияләр белән билгеләнә.

6.4. Республика комиссиясе тапшырылган материалларны министрлыкка материаллар кергән көннән алып 28 эш көне эчендә карый.

Кирәк булган очракта, Министрлык мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган өстәмә мәгълүматны соратып алырга хокуклы. Шул ук вакытта экспертиза үткәрү вакыты озайтылырга мөмкин, ләкин ул 20 эш көненнән дә артмаска тиеш.

6.5. Озату хаты белән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе гариза бирүчегә кулдан бирелә яисә гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма рәвештә, почта адресы буенча, электрон почта адресы белән электрон документ рәвешендә) 5 эш көне эчендә гариза бирүчегә җибәрелә.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының ___________ № ___ боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе рәисе |
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары – Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе рәисе урынбасары |
| Гафуров Рәсим Вилдан улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылма геологиясе бүлегенең әйдәп баручы белгече – Гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе |
| Ахманова Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының углеводород чималы геологиясе бүлеге җитәкчесе |
| Васильева Татьяна Леонидовна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе |
| Вахитов Самат Таһир улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесе |
| Кыямов Альберт Әнәс улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик мохитне мониторинглау буенча әйдәп баручы белгече |
| Лукина Людмила Александровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Мостафина Раилә Хафиз кызы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе |
| Полушин Владислав Леонидович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик мохит мониторингы бүлеге җитәкчесе |
| Чеснокова Ирина Валерьевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе |
| Чинарев Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Минерал чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе |
| Шутникова Светлана Анатольевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе |